КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 3 июль г.Казань № 537

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү тәртибе турында» 2019 ел, 31 октябрь, 979 нчы карары белән расланган Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы башкара торган Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү тәртибе турында» 2019 ел, 31 октябрь, 979 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 14 декабрь, 1134 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы башкара торган Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура

спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «30 яшькә кадәр (30 яшьне кертеп)» сүзләрен «35 яшькә кадәр (35 яшьне кертеп)» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә хуҗалыкны төзекләндерү өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү, саклау, туктату турындагы карар оешма боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Хезмәткәрләрнең – яшь белгечләрнең хуҗалыкны төзекләндерү өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне алу хокукы хәрби хезмәткә чакыру буенча хәрби хезмәттән яки альтернатив гражданлык хезмәтеннән азат ителгән көннән өч айдан да соңга калмыйча эшкә урнашу шарты белән Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итү яки альтернатив гражданлык хезмәте чорында саклана.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин